**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**ОТВЕТЫ**
**2023-2024 учебный год**

**11 класс**

***I.*** **Борынгы сүзләрне хәзерге татар теленә тәрҗемә итегез./** Переведите древнетюркские слова на современный татарский язык. (*10 баллов. За первый и вторые ответы по 4 балла, за третий ответ – 2 балла*)**.**

Гомумтөрки телдә **йĕттĕ** – сан атамасы. Хәзерге татар телендә ул тулаем мәгънәсен саклаган, әмма фонетик үзгәреш кичергән. Әлеге санны һәм аннан ясалган дистә атамасын языгыз. **(4 балл)**

**Җиде, җитмеш**

Гомумтөрки телдә **тоққуз** сүзе – сан атамасы. Хәзерге татар телендә ул тулаем мәгънәсен саклаган, әмма фонетик үзгәреш кичергән. Әлеге санны һәм аннан ясалган дистә атамасын языгыз. **(4 балл)**

**Тугыз, туксан**

Гомумтөрки телдә **айығ / адығ** сүзе – кыргый хайван атамасы. Хәзерге татар телендә ул мәгънәсен саклаган килеш кулланыла, әмма фонетик үзгәреш кичергән. Әлеге кыргый хайван атамасын языгыз. **(2 балл)**

**Аю**

**II. Татар телендә гарәп теленнән кергән *хәрам* һәм шул ук сүздән ясалган *әрәм* сүзләре кулланыла. Әлеге сүзләр арасында нинди аерма бар? Тел белемендә бу күренеш ничек дип атала? Җавабыгызны дәлиләгез, 3 мисал белән раслагыз**. / В татарском языке употребляется слово *хәрам* и производное этого слова *әрәм.* Какое отличие существует между этими словами? Как называется данное лингвистическое явление? Обоснуйте свой ответ и приведите 3 примера. (*15 баллов. За верную этимологию и объяснение значениия слова 7 баллов; за определение термина – 5 б.; за каждый пример по 1 б..* **)**

**Хәрам** - тыелган нәрсә; законсызлык.
**Әрәм** - юкка тотылган, файдасызга киткән, кирәкмәгәнгә сарыф ителгән нәрсә.
Беренче сүз – гарәп алынмасы, икенчесе - татар теле җирлегендә [х] авазы төшеп калу юлы белән ясалган берәмлек.
Бу - фонетик ысул белән сүз ясалышы.

**III. Сүзләрнең сүз ясалыш чылбырын языгыз. Һәр чылбыр ахырында түбәндә бирелгән сүзләр булсын**. / Запишите словообразовательные цепи, в конце

которых стоят предложенные ниже слова. **(5 баллов.** *За каждый правильный вариант по 2,5 б.).*

*Яшелчәчелек, башлангыч*

**Яшел – яшелчә – яшелчәче – яшелчәчелек.**

**Баш – башла (н) - башлангыч**

**IV. Сүзләрнең русча тәрҗемәсен языгыз**. / Переведите слова на русский язык (**10 балл)** . *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

*Дәгъва, кысрыклау, баскыч, тәхет, күбәләк, бозу, заманча, рәссам, биеклек, гаделлек*

Претензия, теснить, лестница, трон, бабочка, испортить, современный, художник, высота, справедливость

**V. *Омоним* һәм *антоним* терминнарына билгеләмә бирегез /** Дайте определение терминам *омоним* и *антоним* **(5 баллов.** *За каждый правильно данное определение по 2,5 балла).*

Омоним - язылышлары, әйтелешләре бертөрле, әмма мәгънәләре белән аерыла торган сүзләр (тиен-тиен). Төрләре: саф лексик омоним, омограф, омоформа, омофон.

Антоним – капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (көн-төн). Төрләре тел антонимнары, контекстуаль антонимнар (антитеза, оксюморон).

**VI. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап языгыз**. / Выберите из предложенных слов правильный вариант **(5 баллов.** *За каждый правильный ответ по 1 балла*).

Телнең нечкәлекләрен белү өчен, аны һәркөн (эшләү / **куллану** /тоту) кирәк. Әгәр син үз телеңне белмисең икән, халкыңның мәдәниятен, аның рухи байлыгын (**үзләштерә** / тота / ала) алмыйсың. Моңа мисал итеп К.Г.Паустовскийның туган тел турында әйткән сүзләрен искә алу белән (туктыйм / **чикләнәм** / уйлыйм): “Үз иленә булган мәхәббәтне үз теленә булган мәхәббәттән башка күз алдына китереп булмый”.

Әйе, туган телне белмәү – (**наданлык** / гадилек / беркатлылык). Үз телеңне, үз мәдәниятеңне белмәү яхшы (чара / **гамәл** / әйбер) була алмый. (Ф. Яруллин)

**VII. Төшеп калган сүзләрне языгыз /** Впишите пропущенные слова **(5 баллов**. *За каждый правильный ответ по 1 балла.)*

1. Юридик эш кәгазьләре, карар, беркетмә, аңлатма, ышаныч язуы, акт, белдерүләр **РӘСМИ** стильдә язылалар. 2. Тиңдәш кисәкләрне, җөмләләрне үзара теркәү өчен кулланылган сүз **ТЕРКӘГЕЧ** дип атала. 2. Кешеләрнең тойгы-кичерешләрен аңлата торган сүзләр төркеме **ЫМЛЫКЛАР** дип атала. 4. **ЯСАГЫЧ** кушымчалар бер сүздән үзгә мәгънәле икенче сүз ясыйлар. 5. Тотрыклы әйтелмәләрне өйрәнә торган фән **ФРАЗЕОЛОГИЯ** дип атала.

**VIII. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез. Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. /** Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения Сделайте морфологический разбор слов в предложении (**25 баллов**. *За каждое задание по синтаксическому разбору по 5 баллов. За каждый правильный ответ по морфологическому разбору по 1 баллу.)*

.

*Кешене никадәр азрак белсәң, ул шулкадәр серлерәк тоела икән бит. (М. Галиев)*

*Кешене* - туры тәмамлык; *никадәр* - күләм хәле; *азрак* - күләм хәле; *белсәң* – иярчен җөмләнең хәбәре; *ул* – ия; *шулкадәр* - күләм хәле; *серлерәк* – рәвеш хәле; *тоела икән бит* – хәбәр.

2. Баш җөмлә

*нихәтле – шулхәтле, парлы мөнәсәбәтле сүз*

*1. Аналитик иярчен күләм җөмлә*

Кешене - тамыр, урт. исем, төшем килешендә, берлек санда
никадәр - кушма рәвеш, күләм-чама рәвеше
азрак -тамыр рәвеш, күләм-чама рәвеше
белсәң – иярчен җөмлә хәбәре
ул – тамыр, алмашлык, зат алмашлыыгы, 3 зат, берлек санда
шулкадәр - кушма рәвеш, күләм-чама рәвеше
серлерәк – ясалма сыйфат, асыл сыйфат, чагыштыру дәрәҗәсендә
тоела - тамыр фигыль, хәзерге заман хикәя фигыль, 3 зат, берлек сан, барлыкта, (төшем юнәлешендә)
икән, бит - модаль сүзләр (бит – кисәкчә).

**XIX.** ***Суны - таяк белән, кешене тел белән үлчиләр*** **мәкален сез ничек аңлыйсыз? Шушы мәкальдә әйтелгән үз мөнәсәбәтегезне 80 сүздән ким булмаган язмада белдерегез. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез./** Как вы понимаете пословицу *Воду измеряют палкой, человека - языком*? Опираясь на это **выражение,** напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов). Выражая свое отношение приведите не менее 2 довода-примера *(20 баллов).*

Әлеге мәкальдә кешене бәяләгәндә, аның телне куллану үзенчәлеге зур роль уйнавы әйтелә.

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| *III* | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |